| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 08.12.2023 | г. Казань | № 422-40/кс-2023 |

«Үзәк торак-коммуналь идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе өчен эчәргә яраклы суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2020 № 366-164/кс-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларны 2024 елга төзәтү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга 2024-2025 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемenә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 08.12.2023 № 53-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе өчен эчәргә яраклы суга 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү турында» 09.12.2020 № 366-164/кс-2020 (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 25.05.2022 № 68-21/кс-2022, 18.11.2022 № 596-170/кс-2022, 13.10.2023 № 331-16/кс-2023 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә иректе файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу

өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
09.12.2020 № 366-164/кс-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.12.2023 № 422-40/кс-2023
карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» ФДБУ өчен эчә торган суга 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Чор | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| 1 | «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» ФДБУ | | |
| 1.1 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге кулланучылары | | |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 31,82 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 33,12 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 33,12 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 34,58 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 37,68** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 37,68 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 43,24 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 42,20 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 42,20 |
| 1.1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 26,52 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 27,60 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 27,60 |
| | | 01.07.2022 башлап 30.12.2023 кадәр | 28,82 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 31,40** |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 31,40 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 36,03 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 35,17 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 35,17 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

<**> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.11.2022 № 596-170/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге